РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«20» апрель 2022 г. г. Альметьевск № 70

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәре Уставына
үзгәрешләр кертү турында

(Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2022 елның 6 маенда RU165071012022001 номер белән теркәлде)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы законга үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының XV бүлеге,2022 елның 1 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2011 елның 22 сентябрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына ( 2012 елның 21 июнендәге 69 нчы номерлы, 2013 елның 04 июлендәге 104 нче номерлы, 2014 елның 02 октябрендәге 139 нчы номерлы, 2015 елның 13 мартындагы 167 нчы номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 29 нчы номерлы, 2016 елның 28 декабрендәге 57 нче номерлы, 2017 елның 27 июлендәге 86 нчы номерлы, 2018 елның 11 маендагы 116 нчы номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 144 нче номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 190 нчы номерлв, 2021 елның 9 февралендәге 21 нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставындагы үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставына кертелгән үзгәрешләрне «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми

принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны шәһәр Башлыгы урынбасары И.Р. Баһмановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Әлмәт шәһәре
Советының 2022 елның 20
апрелендәге 70 нче номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Әлмәт шәһәре Уставына үзгәрешләр кертү турында

1. 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1) җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешен муниципаль контрольне гамәлгә ашыру»;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) шәһәр чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм шәһәр чикләрендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру елкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

в) 20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) Шәһәр территориясен тезекләндерү кагыйдәләрен раслау, тезекләндерү елкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы шәһәр территориясен тезекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен тезекләндерү, шулай ук шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру»;

г) түбәндәге эчтәлекле 43 пункт өстәргә:

«43) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан кишәрлек урманчылыклары составындагы урманчылыкларны төзү, бетерү, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү»;

д) түбәндәге эчтәлекле 44 пункт өстәргә:

«44) җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман тезелеше чараларын гамәлгә ашыру»;

е) 27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27) Шәһәр территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру»;

ж) 36 пунктта «, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге булдыру турында шартнамә тезү хокукына ачык аукцион уздыру» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. 14.1 статьяда:

а) 14.1 статьяның 1 елеше 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча күрсәтелгән торак пункт күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек территориясенә кертүгә китерә;»

б) 14.1 статьясы 2 елешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар җыены үткәрелә торган торак пункт территориясенең бер елеше чикләре Шәһәр Советы карары белән күрсәтелгән өлештәге халыкның мәнфәгатьләрен яклау критериеннән чыгып билгеләнә»;

3.17 статьяның 5 елешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм тезелеш алып бару кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау кагыйдәләре проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яисә капиталь тезелеш объектыннан файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән теренә яисә рехсәт бирү турындагы карарларның проектларына, капиталь тезелеш объектларын тезүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү, реконструкцияләү турындагы карарларның проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь тезелеш объектларыннан рехсәт ителгән файдалануның бер терен һәм мондый файдалануның башка терен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалану һәм тезелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булмаганда яисә шәһәр тезелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә гавами тыңлаулар яки җәмәгать фикер алышулары үткәрелә";

4. 36 статьяның 1 елеше 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе гражданлыгының яисә чит ил гражданлыгының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының гражданлыгы туктатылу-аның нигезендә чит ил гражданы булу яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы»;

5. 42 статьяның 1 елеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгының яисә чит ил гражданлыгының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының гражданлыгы туктатылу- аның нигезендә чит ил гражданы булу яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы»

6. 45 статьяның 1 елешендә:

а) 3 пунктның 11 абзацында «федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлеге төзү турында шартнамә тезү хокукына ачык аукцион үткәрә» сүзләрен тешереп калдырырга.

б) түбәндәге эчтәлекле 3 абзац естәргә:

«-җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыклар составында тезелә торган урманчылыкларны тезү, бетерү, аларның чикләрен

билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итә, шулай ук җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләүне һәм раслауны гамәлгә ашыра»;

в) түбәндәге эчтәлекле 3 пункт естәргә:

«- җирлекнең торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман корылышы чараларын гамәлгә ашыра»; ;

г) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац естәргә:

«- җылылык белән тәэмин итү объектларын тезү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

д) 4 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итү һәм аларда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итү, парковкалар (парковка урыннары) төзүне һәм аларның эшләвен тәэмин итүне, автомобиль транспортында, шәһәр җир есте электр транспортында һәм җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруны, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру елкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру»;

е) 6 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирлек территориясен тезекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру»;

ж) 9 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре шәһәр Башкарма комитеты органнарына мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә бирелергә мөмкин. Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, тикшерүләрне оештыруга һәм уздыруга бәйле мөнәсәбәтләргә карата «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла. «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 9 өлеше нигезендә муниципаль контроль тере муниципаль берәмлек чикләрендә тиешле контроль терләре булган очракта гамәлгә ашырылырга тиеш».

7. 46 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек естәргә:

«8. Башкарма комитет җитәкчесе Шәһәр башлыгына Россия Федерациясе гражданлыгының яисә чит ил гражданлыгының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының гражданлыгы туктатылу турында хәбәр итә - аның нигезендә чит ил гражданы булу яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы»;

8. 50 статьяның 1 елешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгының яисә чит ил гражданлыгының Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының гражданлыгы туктатылу - аның нигезендә чит ил гражданы булу яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы»;

9. 65 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 бүлек өстәргә:

«8. «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм бәяләү принципларын исәпкә алып, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү, административ җаваплылыкка җәлеп итү, лицензияләр һәм башка рөхсәтләр, аккредитацияләү, бәяләүнең һәм экспертизаның башка рәвешләре (алга таба - мәҗбүри таләпләр) муниципаль контроль кысаларында гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне куллануны билгеләү һәм бәяләү тәртибе муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

10.66.1 статьяның 2 өлешендәге 17 пунктын төшереп калдырырга.

11.68 статьяда:

а) 4 елешнең беренче абзацында «эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары ечен бурычлар» сүзләрен «эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен мәҗбүри таләпләр, инвестиция эшчәнлеге субъектлары ечен бурычлар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «инвестиция эшчәнлеге» сүзләрен «башка икътисадый эшчәнлек» сүзләренә алмаштырырга;

12. 81 статьяның 2.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1 Шәһәр бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

1) Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

2) Россия Федерациясенең милли үсеше максатларын һәм гавами хакимият органнары эшчәнлегенең аларга ирешү юнәлешен билгеләүче документлар;

3) шәһәрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

4) шәһәрнең социаль-икътисадый үсеше фаразлары;

5) озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

6) муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары);

13. 83 статьяда

а) 1 елештә «шәһәр халкы» сүзләреннән соң» (яисә аның территориясе елешендә)";

б) 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә әлеге Уставның 14.1 статьясындагы 1 елешенең 1.2 һәм 1.3 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында»

в) 3 елешне төшереп калдырырга;

14. 90 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр Уставы әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында шәһәр Советы карары, алар дәүләт теркәвенә алганнан соң, рәсми бастырып

чыгарылганнан соң (халыкка җиткерелгәннәнә) үз кеченә керә һәм әлеге Уставта каралганча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), шулай ук Россия Юстиция министрлыгы «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» (http://pravo-minjust.ru, http://pravo-минюст.рф) порталында урнаштырыла. Шәһәр Башлыгы шәһәрнең теркәлгән Уставын, шәһәр Советының әлеге Уставка үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турындагы карарын муниципаль берәмлекләр Уставларын теркәү елкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан шәһәр Уставы, муниципаль хокукый акт турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамәләр кергән кеннән җиде көн эчендә бастырырга (халыкка җиткерергә) бурычлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралганча.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов